ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2020 Казан ш. № 358-56/тэ-2020

«РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2021 елга тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «РСК» ҖЧҖ) тарафыннан күрсәтелә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә әлеге карарның кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.12.2020 № 358-56/тэ-2020 карарына кушымта

«РСК» ҖЧҖ тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2021 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

<table>
<tr><td rowspan="2">Т/с</td><td rowspan="2">Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы</td><td rowspan="2">Тариф төре</td><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="2">Җылылык саклау матдәсенең төре</td></tr>
<tr><td>су</td><td>пар</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="5">Казан шәһәре</td></tr>
<tr><td rowspan="3">1</td><td rowspan="3">«РСК» ҖЧҖ</td><td colspan="4">Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта</td></tr>
<tr><td rowspan="2">бер ставкалы, сум/Гкал</td><td>01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр</td><td>295,75</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр</td><td>303,04</td><td>-</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="5">Югары Ослан муниципаль районы</td></tr>
<tr><td rowspan="3">2</td><td rowspan="3">«РСК» ҖЧҖ</td><td colspan="4">Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта</td></tr>
<tr><td rowspan="2">бер ставкалы, сум/Гкал</td><td>01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр</td><td>84,48</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр</td><td>87,15</td><td>-</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге